## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“15” ноябрь 2021 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 15 ноябрендә «Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Кызыл Утар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән,тавыш бирү хокукына ия булган, һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Кызыл Утар авылы территориясен чистарту (үлән чабу, куаклар һәм агачлар кисү);

2) урам утларына хезмәт күрсәтү өчен түләү;

3) Кызыл Утар авылында янгынга каршы җир асты су резервуары алу һәм урнаштыру (килешү буенча хезмәт хакы түләү);

4) туң җирне казу өчен бензин белән эшли торган җайланма сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 68 (алтмыш сигез) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 45 (кырык биш) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 45 (кырык биш) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. “Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Кызыл Утар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган, һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Кызыл Утар авылы территориясен чистарту (үлән чабу, куаклар һәм агачлар кисү);

2) урам утларына хезмәт күрсәтү өчен түләү;

3) Кызыл Утар авылында янгынга каршы җир асты су резервуары алу һәм урнаштыру (килешү буенча хезмәт хакы түләү);

4) туң җирне казу өчен бензин белән эшли торган җайланма сатып алу.

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кышлау авыл җирлеге башлыгы Кашшапов А.Х.